КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 3

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасының оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре чыгара торган югары технологияле продукция җитештерүне диверсификацияләүгә һәм экспортка ярдәм итү максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле белән Россия Федерациясе Иминлек Советы Секретаренең 2019 елның 12 мартындагы А21в-172 номерлы күчмә киңәшмәсе беркетмәсенең II бүлегендәге 4.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 гыйнвар, 3 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибе

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең (алга таба – оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре) нәтиҗәле эшләвен үстерү һәм нәтиҗәле эшләү максатларында эшләнде.

2. Мәгълүмати һәм консультация ярдәме Россия Федерациясе законнары нигезендә шундый дип танылган, Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә күрсәтелә.

3. Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтүнең төп максатлары булып тора:

оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләрен диверсификацияләү өчен кирәк булган дәүләт ярдәме чаралары турында, шулай ук ике төрле билгеләнештәге гражданнар продукциясе экспортына ярдәм итү чаралары турында мәгълүматтан оператив рәвештә файдалана алуны тәэмин итү;

оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең хокукый культурасын күтәрүдә ярдәм итү;

Татарстан Республикасында һәм аннан читтә партнерлар һәм заказчылар эзләүгә ярдәм итү.

4. Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә мәгълүмати ярдәм күрсәтү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы Татарстан Республикасында оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме чаралары турында, шул исәптән экспортка ярдәм итү чаралары һәм мондый ярдәм алу шартлары турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмати ярдәм шулай ук Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең электрон почта адресларына мәгълүмати материаллар, норматив хокукый актлар текстлары (яисә аларның реквизитлары), оештыру-методик документлар рәвешендә гамәлгә ашырыла.

5. Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә консультация ярдәме күрсәтү Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан башкарыла:

оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре җитәкчеләре өчен консультацияләр көне;

дәүләт ярдәме, шул исәптән экспортка ярдәм итү чараларын алу өчен конкурс документларын бастырып чыгарганнан соң 10 календарь көн эчендә семинарлар;

оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләрен милли проектларда катнашуга җәлеп итү буенча семинарлар, түгәрәк өстәлләр.